ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.07.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1450**

2016-2020 елларга Зеленодольск районында яшьләр сәясәтен үстерү турында муниципаль программага үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районында яшьләр сәясәтен планлы һәм һәрьяклап үстерү максатларында, шулай ук «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын, Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү турында» 2015 елның 10 июлендәге 538 номерлы карарын, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 гыйнварындагы 74нче номерлы карары белән расланган 2017-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районының «Мәдәният үсеше нокталары» мәдәният үсеше муниципаль программасына әлеге карарга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ЯҮМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге җитәкчесенә. әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В.Лулаковка йөкләргә. Лулакова.

Җитәкче Д.А. Сапожников

1нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
15.07.2019 № 1450

**Программаның паспортында «Күләме һәм финанслау чыганаклары» пунктының 5 нче графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** «Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».